# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Әгер авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**25 октябрь 2022 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Уставы нигезендә 2022 елның 25 октябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

« Сез 2023 елда 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әгер авылында Җәлил һәм Совет урамнарында вак таш җәелгән юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 66 кеше кертелгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 51.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 48, «КАРШЫ» позициясе өчен 3 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

« Сез 2023 елда 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әгер авылында Җәлил һәм Совет урамнарында вак таш җәелгән юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).”

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Тымытык авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге башлыгы Э.Х. Гыйләҗева